*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*Март , 2026 ел*




***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***



## Март

Март аена калган икән
Кышның соңгы бураны.
Көчемнән генә килми шул
Туктатыр идем аны.
Табигать инде күптән
Язны көтеп зарыккан.
Яр буенда үскән талның
Песиләре дә чыккан.
Күптән язны көтәбез
Килсен әйдә ул безгә.
Ягымлы язлар телим
Сезнең һәрберегезгә.
Җаен искә төшерербез
Март ае бураннарын.
Игеннәр күкрәп үссен
Шул минем планнарым.

## Март аена истәлекле даталар

1 – Наркоманиягә һәм наркобизнеска каршы халыкара көрәш көне.

Бөтендөнья гражданлык оборонасы көне.

8 – Халыкара хатын-кызлар көне.

20 – Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм торак-коммуналь хужалык хезмәткәрләре көне.

21 – Нәүруз бәйрәме.

27 – Халыкара театр көне.

Россия эчке гаскәрләре көне.

30 – Җирне саклау көне.

## Март аена халык сынамышлары

Мартта күк күкрәсә, салкыннар көтегез.

Күк күкрәмичә генә яшен күрсәгез, җәй салкын булыр.

Март яңгырлы булса, гөмбәле җәйгә ишарә.

Мартта суык һәм коры булса, икмәк уңар.

Мартта боз сөңгеләре озын булса, яз озак килер.

Мартта томаннар еш төшсә, яңгырлы җәйгә.

Март ахырында карның тиз эрүе һәм суларның тиз китүе дә яңгырлы җәй билгесе.

# Март мәшәкатьләре: язны каршы алыйк

Март – әле кыш та түгел, яз да түгел кебек. Әмма нәкъ менә шушы айда башкарылган эшләр җәйге уңышка нигез сала. Яз соңрак килсә дә, куркырга кирәкми. Халык юкка гына: «Соңлап килгән яз алдамый!» – дип әйтмәгән. Кар акрынлап эри башлый, кояш җылырак карый, бакчачының күңеле дә уяна.

Бүген бакчага күз салыйк, мартта нәрсәләр эшләргә кирәклеген барлап чыгыйк.

**Март – кар сулары ае**

Су җыябыз, бәрәкәт җыябыз

Көндез кояш җылыта, төнлә суыта. Кар эри дә, яңадан ката. Шушы вакытта иң мөһим эшләрнең берсе – су җыю. Бакча кишәрлегендә кар суын мөмкин кадәр күбрәк саклап калырга тырышыгыз. Чөнки язгы дым – җәйге уңышның яртысы дигән сүз. Барлык буш мичкәләрне, чиләкләрне, савыт-сабаларны кар белән тутырыгыз. Җиләк-җимеш куаклары тирәсенә өстәмә кар өегез. Су җыелып, тамырлар черү куркынычы булган түбән урыннарда вак кына канаулар ачыгыз. Авыл кешесе белә: язгы кар суы – тереклек суы. Ул җирне туендыра, туфракны йомшарта, үсемлекләрне уята.

**Кош оялары – бакчаның тере сакчылары**

Кар тулысынча эреп беткәнне көтеп тормыйк – кошлар иртәрәк кайта. Сыерчыклар, сиртмәкойрыклар бакчага корткычларны кимерергә ярдәм итәчәк. Оя урнаштырганда:

- Аны агачка яки нык колгага беркетегез.
- Бераз алга авыштырып куегыз – яңгыр суы кермәсен.
- Тишеге көньяк яки көньяк-көнчыгышка карасын.
- Песиләрдән саклау өчен, кәүсәгә тимерчыбык бәйләгез яки чәнечкеле куак ботаклары белән уратып куегыз.

Кошлы бакча – җанлы бакча. Иртә язда сыерчык сайравын ишетү – үзе бер шатлык!

**Орлыклар һәм үсентеләр турында онытмыйк**

Март – тәрәзә төпләрендә «бакча» үстерә торган ай. Помидор, борыч, баклажан орлыкларын чәчү өчен иң кулай вакыт.

Орлыкларны алдан сайлап, җылы суда яки махсус эремәдә бүрттереп алыгыз. Туфрак җиңел, һава үткәрүчән булсын.

Үсентеләргә яктылык җитсен өчен, мөмкин булса, өстәмә лампа кулланыгыз. Язгы кояш әле көчсез, шуңа күрә тәрәзә төбендәге нәни үсентеләрне сак кына карагыз: артык су да, артык корылык та килешми.

**Март – сабырлык һәм өмет ае**

Бакча әле йокымсырый кебек, әмма аның йөрәге тибә башлаган инде. Без дә вакытында ярдәм итсәк – җәй көне мул уңыш белән сөендерер.

Халык әйтмешли, язгы бер көн – ел туйдыра. Шуңа күрә мартның һәр җылы көнен файдалы итеп уздырыйк. Кар суын да җыеп калыйк, агачларны да карап чыгыйк, кошларга да оя элеп куйыйк. Шунда бакчабыз да, күңелебез дә гөрләп чәчәк атар!

# «Умырзая » бию төркеме бездә кунакта

Балалар бакчасы һәм мәктәп белән дәвамчанлык планы нигездә, балалар бакчасына мәктәпнең башлангыч сыйныфларның «Умырзая» бию төркеме кунакка килде. Укучылар матур биюләр башкардылар, М.Җәлилнең «Кызыл ромашка» һәм «Карак песи» шигырьләрен сәхнәләштереп күрсәттеләр. Мәктәпкә әзерлек һәм зурлар төркеме «Чишмә» биюен, «Әтәч» , «Маэмай» җырларын башкардылар. Очрашу уңай тәэсир калдырды,дәвамлы булсын.







***Наласа мәктәбе ир-егетләренә, профком җитәкчесе Рафиль Нуретдин улына коллектив кызлары исеменнән олы рәхмәтебезне җиткерәбез.***





*Хөрмәтле хатын - кызлар !*

*Сезне язның беренче бәйрәме – 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне белән котлыйбыз! Шушы гаҗәеп гүзәл бәйрәм көнендә, сезнең тормышыгыз яхшылык һәм яктылык, якыннарыгызның күңел җылысы һәм игътибары белән тулып, йөзләрегез елмаюдан яктырып, нур чәчеп торсын. Һәрчак шулай тырыш, эш сөючән, төгәллек һәм матурлыкның нәфис өлгесе булып калуыгызны дәвам итегез. Яз сулышы гаиләгезгә бәхет, уңышлар, яхшы кәеф, зур шатлыклар, муллык алып килсен, күңелегезгә сабырлык, саулык-сәламәтлек, йортыгызга иминлек-бәрәкәт китерсен! Өстәлләрегез ямьле, аш-суларыгыз тәмле, бәйрәмегез мөбәрәк булсын!*

*Кояш көлә, шундый матур дөнья,*
*Бәйрәм рухын сизә күңелләр.*
*Хатын-кызлар! Бәйрәмегез белән*
*Тәбрик итәбез чын күңелебездән.*

*Иң изге теләкләр белән*
*Наласа урта мәктәбе ир-егетләре, профком*

*8 Марта*



# «Әнием - кадерлем»

Балалар бакчасында мәктәпкә әзерлек һәм өлкәннәр төркемендә «Әнием - кадерлем» бәйрәм чарасы узды. Бәйрәмебезнең беренче өлеше җыр-биюләр, шигырьләр белән үрелеп барса, икенче өлешендә әниләр белән күңелле уеннар оштырылды. Бу чара балалар һәм әниләр өчен истә калырлык күңелле бәйрәм булды. Өченче өлешендә Россия халыклары бердәмлеге елы уңаеннан,балалар бик матур милли киемнәр белән күмәк бию биеделәр. Әниләренә үз куллары белән ясалган бүләкләрен тапшырып, истәлеккә фотога төшеп, бәйрәмебезне тәмамладык.









**Кечкенәләр төркеменең бәйрәм иртәсеннән матур мизгелләр.**

Без беләбез, җылы язының
Иң беренче бәйрәме -
Әниләр, әби, апалар
Хатын-кызлар бәйрәме.







# «Суган утырту, тәҗрибәләр»












Балаларның табигатькә тотрыклы кызыксынуын формалаштыру, шулай ук экологик белемле бала тәрбияләү өчен уңайлы шартлар тудыру максатыннан, төркемнәребезнең тәрәз төпләрендә яшелчә, культуралы үсемлекләр утыртылды. Кояш көннән-көн югарырак җылыта, көннәр озыная . Бакчачыларның орлык чәчү вакыты җитә. Балалар бакчасында тәрәзә төбендә кечкенә генә бакча ясау бик күңелле эш, аеруча кыш яки яз айларында. Табигатьнең яңа бүләкләрен татып кына калмыйча, аның төсләренә, яшеллегенә дә сокланасы килә. Ләкин беренче язгы яшеллек синең тәрәзә төбендә өлгерсә, аннан да күңеллерәк нәрсә юк. Тәрәзә бакчасы ярдәмендә балалар бүлмә шартларында үсемлекләрне ничек кайгыртырга, үсемлекләр үсеше өчен яктылык, җылылык, туфрак дымы кирәклеге турында яңа белемнәр алалар, танып белү һәм иҗади сәләтләрен үстерәләр.





# «Бакчабызда театр көне!»















Театраль эшчәнлек – балалар иҗатының иң киң таралган төре. Образга кереп, бала төрле рольләрне уйный, аннан үзенә эмоциональ ләззәт ала. Театраль эшчәнлек шөгыльләре баланың кызыксынуларын, сәләтләрен һәм мөмкинлекләрен үстерә, бала яңа белемнәр алырга ашкына, үз максатына ирешергә ярдәм итә.Бүген безнең балалар бакчасында театр көне узды! Тәрбиячеләр балалар белән әңгәмәләр үткәрделәр: «Нинди театрлар була?» , «Театрда үзеңне ничек тотарга» «Курчак театры булдыру тарихы» Балалар театр атрибутларын һәм әкият персонажларының төрле костюмнарын кулланып, әкиятләр буенча драматизация уеннарын рәхәтләнеп уйнадылар. Театр артисты булу һәр балага да ошады.

# Туган көн белән котлыйбыз!

Март аенда кечкенәләр төркеменә йөрүче кызларыбыз Мөхәммәтҗанова Зәлия, Иванова Изабелла, акыллы егетебез Идрисов Аязны, зурлар төркеменә йөрүче кызыбыз Гайнетдинова Камилә, егетләребез Гайнетдинов Риназ, Халиуллин Райнур туган көннәрен билгеләп үттеләр. Балаларга сәламәт, озын гомерле, бәхетле, акыллы, тәүфыйклы булып үсүләрен теләп калабыз.







***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Хусаенова Р.Н., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары****: Галиуллина А.Ф., Гафурова Р.А., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР,Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*